КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 март г.Казань № 335

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче; 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче; 2017 ел, 26 май, 310 нчы; 2018 ел, 27 ноябрь, 1060 нчы; 2020 ел, 12 март, 186 нчы; 2020 ел, 12 ноябрь, 1015 нче; 2021 ел, 3 февраль,

53 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрлә-ренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктта:

өченче абзацта татар текстында «Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган» сүзләрен «Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин